**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Биләркүл авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

«08» декабрь 2025 ел №10

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биләркүл авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 апрелендәге 20 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон, Биләркүл авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биләркүл авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биләркүл авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 апрелендәге 20 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) физик затның Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булуы яисә вафат булуы турында игълан ителүе (мондый физик затка карата банкротлык турында эш кузгатылган очрактан тыш):

Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелмәгән салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлар өлешендә;

Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артыграк күләмдә, шул исәптән мирас Россия Федерациясе милкенә күчкән очракта да, бурыч өлешендә;

Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артмаган күләмдә бурыч өлешендә мондый физик зат вафат булганнан соң өч ел узгач һәм салым органында мондый мөлкәтне мирас итеп алу факты турында мәгълүмат булмаганда;».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru һәм җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биләркүл авыл җирлеге
Советы рәисе В.С.Оренбургов